**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 21 гыйнвар № 31

г. Казань

2016 елга Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 елда Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килә торган чыгымнарны финанслашу максатларында, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү турында» 2015 ел, 29 декабрь, 1477 нче карары нигезендә һәм сәламәтлек саклау өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

2016 елга Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү тәртибен;

2016 елга Россия Федерациясе гражданнарына, шул исәптән Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килә торган чыгымнарны финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәмен күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны «Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте

территориаль фонды» дәүләт учреждениесе тарафыннан финанслар белән тәэмин итү турындагы шартнамәнең бертип формасын билгеләнгән тәртиптә эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«2015 елга Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 15 гыйнвар, 11 нче;

«Россия Федерациясе гражданнарына, шул исәптән Россия Федерациясенең бүтән субъектлары территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелмәгән югары технологик медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килгән чыгымнарны финанслашу максатында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану турында» 2015 ел, 23 июнь, 455 нче.

4. Бу карарның гамәле 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\31.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 21 гыйнвар, 31 нче карары белән расланды

**2016 елга Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип 2016 елда Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәмен күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү түбәндәгеләр хисабыннан гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына югары технологияле медицина ярдәмен күрсәтүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды (алга таба – Фонд) бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы;

Россия Федерациясе гражданнарына, шул исәптән Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәмен күрсәткәндә барлыкка килә торган чыгымнарны финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субсидияләр.

Россия Федерациясе гражданнарына, шул исәптән Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәмен күрсәткәндә барлыкка килә торган чыгымнарны финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану федераль законнар нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәмен күрсәтүне финанслар белән тәэмин итүгә Фонд бюджетына бюджетара трансфертлар бирүгә Татарстан Республикасы бюджетының бюджет

ассигнованиеләре күләме тиешле финанс елына югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә норматив чыгымнардан һәм хезмәтләр күрсәтү күләмнәреннән чыгып билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Фонд бюджетына бюджетара трансфертларны тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирә.

5. Фонд законнар нигезендә медицина оешмалары белән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган бертип форма буенча Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү турында шартнамә төзи.

6. Фонд акчаны медицина оешмаларына түбәндәге шартлар үтәлгәндә күчерә:

медицина оешмалары Фонд күчергән акчадан мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү өчен файдаланса;

медицина оешмалары мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарның һәм медицина хезмәтләре күрсәтүнең аерым исәбен алып барса;

медицина оешмалары күрсәтелгән югары технологияле медицина ярдәме өчен исәпләрнең шәхсиләштерелгән һәм җыелма реестрларын Фондка хисап аеннан соң килә торган айның 5 еннән дә соңга калмыйча кертсә.

7. Медицина оешмаларына аванс бирү Фонд бюджетына бюджетара трансфертлар кергән көннән алып биш көн эчендә билгеләнгән дәүләт йөкләмәсенең уртача айлык күләменнән иң күбе 50 процент күләмендә гамәлгә ашырыла.

8. Фонд медицина оешмалары керткән исәпләр реестрларына билгеләнгән тәртиптә медицина-икътисадый экспертиза үткәрә һәм ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 20 сеннән дә соңга калмыйча, аларга түләүне гамәлгә ашыра. Акча күчерү Фондның Россия Федерациясе гражданнарына югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүе турындагы шартнамәдә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

9. Медицина оешмалары мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү өчен алган акчаны алар югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүдә катнаша торган медицина хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүгә, югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү өчен дару чаралары һәм тотыла торган материаллар сатып алуга, медицина оешмасын тоту чыгымнарына түләүгә җибәрә.

10. Фонд ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 20 сеннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына әлеге министрлык билгеләгән форма буенча Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Фонд җибәргән Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен тоту турында хисап кертә.

11. Бюджетара трансфертлардан максатка ярашсыз файдалану бюджет турындагы законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

12. 2017 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган, әлеге Тәртип нигезендә алынган бюджетара трансфертлар 2017 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Бу Тәртип нигезендә алынган бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемнә күчерелмәсә, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты керемнә, Россия Федерациясе финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне саклап, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә кайтарылырга тиеш.

13. Фонд һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү өчен медицина оешмаларына кергән акчадан максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны тәэмин итә.

______________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 21 гыйнвар, 31 нче карары белән расланды

**2016 елга Россия Федерациясе гражданнарына, шул исәптән Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килә торган чыгымнарны финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибе**

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе гражданнарына, шул исәптән Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килә торган чыгымнарны финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану механизмын билгели.

2. Субсидияләр федераль бюджеттан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ачылган бердәм исәпкә киләләр.

3. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчаны тотуны Казначылыкта ачылган шәхси исәп аша Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы гамәлгә ашыра.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына бу Тәртиптә күрсәтелгән акчаны бирү, федераль бюджеттан акча кергәннән соң, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм бюджет йөкләмләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Казначылыктан субсидияләр килү турында мәгълүмат алынганнан соң, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгын финанслауга чыгымнар тәртибен Казначылыкка кертә.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Казначылыкның акча килү турындагы мәгълүматы нигезендә югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт йөкләмәсен финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләрне Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының (алга таба – субсидия алучылар) Казначылыкта ачылган, бюджет һәм автоном учреждениеләр акчасы белән операцияләрне исәпкә алу өчен билгеләнгән шәхси исәпләренә күчерә.

7. Субсидияләр югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт йөкләмәсен финанслар белән тәэмин итүгә федераль бюджет акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибе һәм шартлары турындагы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм субсидия алучылар арасында төзелгән килешүләр нигезендә бирелә.

8. Субсидия алучылар мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә субсидия акчасын югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүдә катнаша торган медицина хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүгә, югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү өчен дару чаралары һәм тотыла торган материаллар сатып алуга, медицина оешмасын тоту чыгымнарына түләүгә җибәрә.

9. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы субсидия алучыларның бирелгән субсидияләрне өлешчә яки тулысынча кире кайтаруын түбәндәге шартлар булганда тәэмин итә:

күрсәтелгән акчага ихтыяҗ булмау (кимү);

субсидия алучыларның дөрес булмаган хисаплылык тапшыруы;

субсидия алучыларның акчадан максатчан файдаланмавы.

10. Бирелгән субсидияләр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тиешле таләбен алган көннән соң 15 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия бирү турындагы килешүдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр субсидия алучы тарафыннан хисап елыннан сон килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия алучылар субсидияне кайтару вакытын бозганда, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацларында билгеләнгән вакыт тәмамланган көннән соң 30 көн эчендә законнарда билгеләнгән тәртиптә акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча чаралар күрә.

11. Субсидия алучылар:

федераль бюджеттан субсидия финанс чыганагы булып торган югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү буенча чыгымнарның, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтелгән пациентларның аерымланган исәбен алып баралар;

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 5 сеннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртип һәм формалар нигезендә югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү турында хисап һәм финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы субсидияләр булган чыгымнар турында хисап кертәләр.

12. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына түбәндәгеләрне кертә:

2016 елның 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган тәртипкә һәм формага ярашлы рәвештә субсидия бирү шартларын үтәү турында хисап;

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 сыннан дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган тәртипкә һәм формаларга ярашлы рәвештә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы арасындагы килешүдә билгеләнгән субсидия алучыларның субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече мәгънәсенә ирешү турында хисап һәм финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы субсидия булган Россия Федерациясе субъектының бюджет чыгымнарын гамәлгә ашыру хакында хисап.

13. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертелә торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләнә.

14. Субсидия алучыларның субсидияләрдән максатчан файдалануын тикшерүдә тотуны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы гамәлгә ашыра.

15. Бу карар нигезендә бирелгән акчадан максатка ярашсыз файдалану Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.

16. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучыларның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерү үткәрә.